# “Теремкәй” әкиятенә сәяхәт.



Гараева Лилия Маратовна

**Максат**: Тигезлек турында күзаллауны, төрле фигураларны дөрес итеп урнаштыруны ныгыту; төрле биеклектә булган предметларның арасында зурлык мөнәсәбәтләре урнаштыруны үстерү; предметларны күләме буенча чагыштыруны ныгыту.

**Җиһазлар:** “Теремкәй” өе, бака, тычкан, куян, төлке, бүре,аю уенчыклары, өй рәсемнәре, кубиклар, машиналар, пазллар.






Теремкәй янына **бака- Бакылдык** килә.
Терем- теремкәй, теремдә кем яши?- дип сораган. Аңа җавап бирүче булмый. Бака теремкәйгә керә дә шунда яши башлый.



Көннәрдән бер көнне теремкәй яныннан **тычкан- Чыелдык** үтеп бара икән, ул туктаган да сораган:
Терем- теремкәй, теремдә кем яши?- дигән.
Мин, бака- Бакылдык, монда яшим!- ди.
Мине дә керт әле ди тычкан!
Кертермен!- ди бака, тик моның өчен мин сина бер бирем кушам- ди.



Балалар өйне дөрес итеп урнаштырырга кирәк. Әйдәгез әле, урнаштырып китик.




Бака тычкан-
Чыелдыкны теремгә
кертә.
Алар теремдә бергә
яши башлыйлар.



Бервакыт терем янынннан **куян-Куркаккай** узып бара, теремгә кертүләрен сорый. Аңа бирем бирәләр.

Өстәлдә биек һәм тәбәнәк куяннар куелган. Дөрес басканнармы икән алар?







Теремкәй яныннан **төлке- Хәйләбай** узып бара, теремкәйгә кертүне сорый,әйдәгез әле, балалар, төлке-Хәйләбайны теремкәйгә кертү өчен, без физкультминутка ясап алыйк.



Физкультминутка.
Бергәләп басыйк әле,
Түгәрәк ясыйк әле.
Менә нинди түгәрәк!
Бик кечкенә түгәрәк!
Кулны кулга тотынып,
Артка таба барабыз.
Менә нинди түгәрәк!
Бик зур түгәрәк!
Уңга таба барабыз,
Тырышабыз барыбыз!
Ә хәзер сулга китик,
Йөрүне дәвам итик.
Түгәрәктә йөрибез.
Бер дә карап тормыйбыз.
Менә шулай ял иттек,
Вакыт күңелле үтте.



Көн арты көн үткән, бервакыт теремкәй яныннан **бүре** узып бара икән. Теремкәйне күргән дә, аның янына барган. Кем яшәве турында кызыксынган. Аңа бака, тычкан, куян, төлке җавап кайтарганнар! Бүре дә алар белән яшәргә теләге барлыгын белдергән. Җәнлекләр үзләре куйган биремне үтәгәч  кертербез дигәннәр.

Өстәлдә кубикларны, машинаны чагыштыру.
Кайсы күбрәк, кайсы азрак?









Терем янында
**Аю** пәйда була!
Өйгә кертүне
сорый. Ләкин
аю теремгә
сыймый.



Балалар әйдәгез, аюга пазллардан өй ясап бирик.

Аю да өйле булды.

# Игътибарыгыз өчен зур

